Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXVIII-3**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 1декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 1 маддәсендәге 7 пункты, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль законның 1 маддәсендәге 4 пунктының б пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 06.10.20 № II-2 карары редакциясендә) Нигезләмәнең 12 маддәсендәге 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

"Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар, түбәндәге очраклардан гайре, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә (алга таба әлеге маддәдә - җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар):

- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җәмәгатьчелек

фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин;

- җирлекнең генераль планына бер яки берничә торак пункт, аларның өлешләре территориясенә карата үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар территория чикләрендә үткәрелә, аңа карата генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул ителә. Бу очракта җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрү вакыты бер айдан артык була алмый.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы урынбасары

Ф.Г. Әхмәтҗанова